**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об объявлении 2019 года в Республике Татарстан Годом рабочих профессий

В целях популяризации в обществе рабочих профессий, привлечения внимания государственных органов, органов местного самоуправления, бизнес-сообщества, общественных объединений и организаций к вопросам совершенствования профессиональных стандартов и подготовки востребованных квалифицированных кадров **постановляю:**

1. Объявить 2019 год в Республике Татарстан Годом рабочих профессий.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан:
в месячный срок образовать организационный комитет по проведению в Республике Татарстан Года рабочих профессий и утвердить его состав;
в трехмесячный срок разработать и утвердить план основных мероприятий по проведению в Республике Татарстан Года рабочих профессий с учетом проводимого в г. Казани в 2019 году мирового чемпионата по профессиональному мастерству по стандартам «Ворлдскиллс».

3. Предложить главам муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан организовать работу по проведению на территориях муниципальных образований мероприятий в рамках Года рабочих профессий.

4. Предложить территориальным органам федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, общественным объединениям и организациям принять активное участие в подготовке и проведении в Республике Татарстан Года рабочих профессий.

5. Республиканскому агентству по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа», республиканским и местным средствам массовой информации обеспечить широкое освещение проведения в Республике Татарстан Года рабочих профессий.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
24 сентября 2018 года
№ УП-687

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2019 елны Татарстан Республикасында Эшче һөнәрләр елы дип игълан итү турында**

Җәмгыятьтә эшче һөнәрләрне популярлаштыру, дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, бизнес-берлекләрнең, җәмәгать берләшмәләренең һәм оешмаларның игътибарын һөнәри стандартларны камилләштерү һәм зур ихтыяҗ булган квалификацияле кадрлар әзерләү мәсьәләләренә җәлеп итү максатларында **карар бирәм**:

1. 2019 елны Татарстан Республикасында Эшче һөнәрләр елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай эчендә Татарстан Республикасында Эшче һөнәрләр елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай эчендә, 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатын уздыруны исәпкә алып, Татарстан Республикасында Эшче һөнәрләр елын уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Эшче һөнәрләр елын уздыру буенча эшне оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Федераль башкарма хакимияте органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Эшче һөнәрләр елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Эшче һөнәрләр елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 24 сентябрь
№ ПУ-687